

Борынгыдан килгән һәм татарларыбыз яратып шогыльләнгән эшләрнен берсе - ат vрчетv. Бу матур һәм акыллы малны яратмый vрчетеп булмый. Темников районы татарларыбыз атны vстерv белән мавыга. Шәйхулла Шәмил улы Поздняков - тобәкнен атлар vрчетv белән ныклап шогыльләнә башлаган хужаларнын чираттагысы.

Авыл кешесенен тормышын жирдән башка кvз алдына китереп булмый. Юкка гына жир кешене туендыра да, киендерә дә дип әйтмиләрдер. Монын шулай икәнлегенә Темников районы Большое Татарское Караево авылында яшәvче Поздняковлар гаиләсе мисалында кvрергә була. Әмма шуны кисәтеп куярга кирәк: әгәр сез атлар vрчетә башларга жыенасыз икән, бизнес-план   киләчәк  эшегезнен әзерлек стартындагы аерылгысыз олеше булачак. Анын тозелешенә кvчкәнче, сезгә, беренче чиратта, бизнес концепциясен билгеләргә кирәк. Шулай, 2019 елда Большое Татарское Караево авылында КФХ башлыгы Шәйхулла Шәмил улы Поздняков хужалыкта атларны алга таба эшкәртv һәм сату очен vстерvне планлаштыра. Башта атчылык vстерv проектын унышлы яклый. Аннан сон, ат vрчетv базасын тозv очен, 3 миллион сум кvләмендә Грант ала. Нәтижәдә, vз акчасына 21 баш яшь терлек сатып ала һәм зур эшкә тотына. Бvгенге кондә бу эш матур гына vсеп килә. 2024 елга атлар санын 60ка кадәр арттырырга планлаштыра Шәмил улы Шәйхулла. Ин моһиме - курыкмау һәм билгеләнгән максатына ышанычлы адымнар белән атлау.
Проект ябык цикл буенча стандарт продукция (ит) һәм ярымфабрикатлар чыгаруны тәэмин итv максатларында табунны vстерvне кvздә тота: азык базасы - товар котvен тоту - житештерv - эшкәртv һәм әзер продукцияне сату.
Республикабызда ат житештерv перспективалы юнәлеш булып тора, чонки халык арасында ана ихтыяж зур. Хәзерге вакытта продуктив атчылык актуаль. Буш котvлекләр булу һәм жирле халык тәжрибәсе Темников районында ат vрчетv vсешенә унай йогынты ясый.

Наиля НАСЫРОВА